КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 24 май г.Казань № б-968

Муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләренә үзгәреш кертү турында Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләү эшен алга таба камилләштерү максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән Муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләренә үзгәреш кертү турындагы Татарстан Республикасы законнары проектларын һәм аларга теркәлгән материалларны тикшерү регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләренә үзгәреш кертү турындагы Татарстан Республикасы законнары проектларын тикшергәндә бу боерык белән расланган Регламентка таянып эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бу боерык белән расланган Регламентка таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 24 май, б-968 нче
боерыгы белән расланды

# Муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләренә үзгәреш кертү турындагы Татарстан Республикасы законнары проектларын һәм аларга теркәлгән материалларны тикшерү регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре чикләренә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы халкы, җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча Татарстан Республикасы законнары белән үзгәрешләр кертелә.

1.2. Бу Муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләренә үзгәреш кертү турындагы Татарстан Республикасы законнары проектларын һәм аларга теркәлгән материалларны тикшерү регламенты Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары) тарафыннан муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләренә үзгәреш кертү турындагы Татарстан Республикасы законы проектын (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү өчен кирәкле муниципаль хокукый актлар һәм башка документлар тикшерелгәндә кулланыла.

## 2. Төп төшенчәләр һәм терминнар

Бу Регламент максатларында түбәндәге төшенчәләр һәм терминнар кулланыла:

муниципаль берәмлек – шәһәр яки авыл җирлеге, муниципаль район, шәһәр округы;

муниципаль берәмлек чиге – муниципаль берәмлек территориясе чикләрен билгели торган линия;

муниципаль берәмлек чикләренә үзгәреш кертү – муниципаль берәмлек чикләрен билгеләү һәм билгеләп кую чаралары комплексы;

муниципаль берәмлек чикләре урнашу урыны тасвирламасы – муниципаль берәмлек чикләре, арадаш җирдән файдаланулар турындагы мәгълүматларның текст формасындагы сурәтләнеше, шулай ук муниципаль берәмлек чикләре үтә торган җирлекнең урынын билгели торган тасвирлама;

муниципаль берәмлек чикләренең карта-схемасы – муниципаль берәмлекнең урнашу урынын, күләмен һәм чикләрен график рәвештә чагылдыра торган документ;

эшләрне башкаручы – чикләр тасвирламасының график һәм текст өлешләрен эшләүгә контракт (шартнамә) нигезендә эш башкаручы юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр;

муниципаль берәмлекне территориаль планлаштыру документлары – муниципаль районнарны территориаль планлаштыру схемалары, җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары.

## 3. Документлар һәм материаллар

3.1. Закон проектын тикшерү өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы ярдәмендә түбәндәге документлар һәм материаллар җибәрелә:

титул битендә муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләренә үзгәреш кертү турында закон проектын (чикләр тасвирламасының график һәм текст өлешләрен теркәп) керткән закон чыгару инициативасы хокукына ия субъект (субъектлар) күрсәтелгән закон проекты тексты;

эшләрне башкаручы белән төзелгән чикләр тасвирламасының график һәм текст өлешләрен эшләүгә контракт (шартнамә);

эшләрне башкаручы турындагы мәгълүматлар, шул исәптән эшләрне башкаручыга бирелгән кадастр, җир төзелеше һәм проект эшләрен башкаруга лицензия;

муниципаль берәмлекнең үзгәреш кертелгән чикләре өлешенә (өлешләренә) карата мәгълүматлар бирелгән XML-документлар;

закон проектына закон белән җайга салу предметын үз эченә алган һәм тәкъдим ителә торган закон проекты концепциясе бәян ителгән аңлатма язуы;

әлеге закон кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәреш кертелергә якә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге;

финанс-икътисадый нигезләү;

чагыштырма таблица.

3.2. Закон проектына шулай ук муниципаль берәмлекләр чикләренә үзгәреш кертелгәндә 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән процедураның үтәлешен һәм халыкның ризалыгын раслый торган документлар һәм материаллар теркәлә, шул исәптән:

чикләргә үзгәреш кертү инициативасын тәкъдим итү турындагы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары;

131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда муниципаль берәмлек чикләренә үзгәреш кертү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү яки тавыш бирүне үткәрү турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары;

ачык тыңлаулар билгеләү турында карар бастырып чыгару (халыкка җиткерү) турында белешмә кәгазе;

муниципаль берәмлек уставы нигезендә муниципаль хокукый актлар бастырып чыгарылырга тиешле очракларда, ачык тыңлаулар (тавыш бирү) үткәрү турында карар яки бу турыда мәгълүмат урнаштырылган газета битләренең күчермәләре;

муниципаль берәмлек уставы нигезендә муниципаль хокукый актларны мәгълүмат бирү стендларында урнаштыру юлы белән алар халыкка җиткерелгән очракларда, мәгълүмат бирү стендларының урнашу урыннары һәм саны турында вәкаләтле орган карары, шулай ук ачык тыңлаулар билгеләү турындагы карарны халыкка җиткерү датасы һәм урыны хакында булган, муниципаль берәмлек башлыгының имзасы куелган белешмә кәгазе;

ачык тыңлаулар беркетмәсе;

ачык тыңлаулар йомгаклары буенча бәяләмә;

чикләренә үзгәреш кертелергә тиешле муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының чикләргә үзгәреш кертү турындагы инициативаны хуплау хакында карары;

муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару һәм алар үз көченә керү тәртибе өлешендә уставтан өземтә;

муниципаль берәмлекләр чикләренә үзгәреш кертү турында Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча закон чыгару инициативасы турында муниципаль районның (шәһәр округының) вәкаләтле органы карары.

## 4. Закон проектын тикшерү процедурасы

4.1. Закон проектын тикшерү Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан закон проекты кергән көннән 20 эш көне эчендә аларның компетенциясе чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы закон проектын түбәндәгеләргә тикшерүне гамәлгә ашыра:

текст тасвираламасының чик урнашу урыны карта-схемасы рәвешендә бирелгән график тасвирламасына туры килү-килмәвенә;

муниципаль берәмлек чикләренең характерлы нокталары координатларын Татарстан Республикасы тиешле кадастр районының Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координатлар зонасында куллану предметына;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлары кертелгән җир кишәрлекләре чикләре белән муниципаль берәмлекләр чикләренең һәм торак пунктлар чикләренең кисешкән очраклары булу-булмауга;

башкарылган эшләр нәтиҗәләренең эшләрне башкаручы белән төзелгән контракт (шартнамә) шартларына туры килү-килмәвенә.

4.3. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы закон проектын түбәндәгеләргә тикшерүне гамәлгә ашыра:

үзгәреш кертелә торган муниципаль берәмлек территориясе чикләренең территориаль планлаштыру документларының расланган редакцияләрендәге муниципаль берәмлек чикләре турындагы мәгълүматларга туры килү-килмәвенә;

үзгәреш кертелә торган муниципаль берәмлек территориясе чикләренең җирдән файдалану һәм йортлар төзү кагыйдәләренең расланган редакцияләрендәге муниципаль берәмлек чикләре турындагы мәгълүматларга туры килү-килмәвенә.

4.4. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

муниципаль берәмлекләр чикләренә үзгәреш кертү турындагы муниципаль норматив хокукый актларга хокукый экспертиза ясауны;

халыкның ризалыгын һәм 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән муниципаль берәмлекләр чикләренә үзгәреш кертү процедурасы үтәлешен раслый торган документларны һәм материалларны тикшерүне;

муниципаль берәмлекләр территорияләре составына керә торган торак пунктлар исемлегенең Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрына туры килү-килмәвенә тикшерүне;

муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләренә үзгәреш кертү турындагы Татарстан Республикасы законы проектына хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза ясауны.

4.5. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә закон проектын керткән җирле үзидарә органына тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүе (туры килмәве) турында бәяләмә җибәрә.

4.6. Закон проекты билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта, җирле үзидарә органы җитешсезлекләрне бетерә һәм закон проектын Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына яңадан тикшерүгә җибәрә.

4.7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан закон проектының билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә алганнан соң, җирле үзидарә органы муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен һәм аңа материаллар кертү турындагы закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертә.

---